ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2022 г. Заинск № 495

**«2022-2025 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында»**

Муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше, актуаль социаль, иҗтимагый әһәмияткә ия проблемаларын хәл итүдә иҗтимагый оешмалар мөмкинлекләрен нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыру, гражданнарның социаль куркыныч тәртип формаларын профилактикалау, халык арасында социаль киеренкелекне киметү, социаль партнерлык принципларын һәм үзара җаваплылыкны кертү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законга, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2022-2025 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын (алга таба – программа) кушымта нигезендә расларга.
2. Программа чараларын җаваплы башкаручылар тарафыннан үтәүне тәэмин итәргә.
3. Үз көчен югалткан дип танырга:

3.1. «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3.2. «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү»

муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 23 маендагы 281 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3.3. «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 16 октябрендәге 458 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3.4. «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 14 апрелендәге 220 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3.5. «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 19 июлендәге 469 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

3.6. «2019-2021 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 1600 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 762 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Н.Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Р.Н.Камалова
7-07-66

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 26.09
495 номерлы карарына
кушымта

**«2022-2025 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» муниципаль программасы**

## I. Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| 1.Программаның исеме | «2022-2025 елларга Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларына һәм гражданнарга ярдәм итү» программасы (алга таба - программа) |
| 2. Муниципаль программаның заказчысы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 3. Программаны төп ясаучы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге |
| 4. Үтәүчеләр | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;<br>ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге;<br>Россия «Чернобыль» Берлеге инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасы Татарстан Республикасы оешмасы Зәй район бүлекчәсе;<br>Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең Зәй җирле оешмасы;<br>«Татарстан Республикасы Инвалидлар Җәмгыяте» - Бөтенроссия Инвалидлар Җәмгыятенең Татарстан Республикасы Оешмасының Зәй шәһәр-район оешмасы;<br>Подряд оешмалары |
| 5. Программаны эшләүнең нигезләре | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>"Иҗтимагый берләшмәләр турында" 1995 елның 19 маендагы 82-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Федеральный закон от 5 апреля 2010 года №40-ФЗ<br>«Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 05 апрелендәге 40-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Хәйрия эшчәнлеге һәм волонтерлык (волонтерлык) турында» |

| | |
|---|---|
| | 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон; Зәй муниципаль районы Уставының 45 ст. |
| 6. Программаның максаты һәм бурычлары | Муниципаль районның социаль-икътисадый үсеш бурычларын, актуаль социаль, иҗтимагый әһәмиятле проблемаларын хәл итүдә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның мөмкинлекләрен нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыру, гражданнарның социаль куркыныч тәртип формаларын профилактикалау, халык арасында социаль киеренкелекне киметү, социаль партнерлык принципларын һәм үзара җаваплылык булдыруны гамәлгә кертү.<br>1. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү механизмнарын үстерү.<br>2. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында популярлаштыру.<br>3. Гражданнарның социаль куркыныч тәртипләрен профилактикалауга, авыр тормыш хәлендә булган затларны социаль реабилитацияләүгә юнәлдерелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм формаларын камилләштерү |
| 7. Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | Программа 4 елга исәпләнгән: 2022 – 2025 еллар. |
| 8.Ярдәмче программаларның исемлеге | - Ветераннарга матди ярдәм күрсәтү чаралары;<br>- Инвалидларга матди ярдәм күрсәтү чаралары;<br>- Күрү буенча инвалидларга матди ярдәм күрсәтү чаралары;<br>- ЧАЭС фаҗигасе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга матди ярдәм күрсәтү чаралары;<br>- Матди ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ гражданнар категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары. |
| 9. Программаны финанслау чыганаклары һәм күләме | Муниципаль программаны финанслау тиешле тәртиптә билгеләнгән һәм бүлеп бирелгән күләмдә Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырылачак - 6 565 120 сум, шул исәптән:<br>2022 ел – 250 000 сум;<br>2023 ел – 2 095 040 сум;<br>2024 ел – 2 105 040 сум;<br>2024 ел – 2 115 040 сум.<br>Программа кысаларында Зәй муниципаль районының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларына һәм гражданнарына финанс ярдәме күрсәтү чаралары тормышка ашырыла:<br>- ветераннар хәрәкәтенә ярдәм итү чараларына 1671000 сум күләмендә, шул исәптән:<br>2022 ел – 102000 сум,<br>2023 ел – 523000 сум,<br>2024 ел - 523000 сум;<br>2025 ел – 523000 сум; |

| | |
|---|---|
| | - мөмкинлекләре чикле гражданнарны социаль адаптацияләү чараларына 927000 сум күләмендә, шул исәптән:<br>2022 ел – 72 000 сум,<br>2023 ел – 275000 сум,<br>2024 ел – 285000 сум;<br>2025 ел – 295000 сум;<br>- күрү сәләте бозылган инвалидларны социаль тернәкләндерү чараларына 593120 сум күләмендә, шул исәптән:<br>2022 ел – 56000 сум,<br>2023 ел – 179040 сум,<br>2024 ел – 179040 сум;<br>2025 ел – 179040 сум;<br>- Чернобыль АЭС һәлакәте һәм башка техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга ярдәм итү чараларына 343000 сум күләмендә, шул исәптән:<br>2022 ел – 20000 сум,<br>2023 ел – 111000 сум,<br>2024 ел – 111000 сум;<br>2025 ел – 111000 сум;<br>- мохтаҗ гражданнарга матди ярдәм күрсәтүгә 3021000 сум күләмендә, шул исәптән:<br>2022 ел – 0 сум;<br>2023 ел – 1007000 сум;<br>2024 ел – 1007000 сум;<br>2025 ел – 1007000 сум. |
| 10. Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре) | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан оештырылган чаралар саны арту;<br>Социаль әһәмиятле чараларда катнашкан гражданнар саны арту;<br>Гражданнарның социаль якланмаган категорияләре үсү кимү;<br>Муниципаль район халкының хәбәрдарлык дәрәҗәсе күтәрелү;<br>Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар җитәкчеләре эшен стимуллаштыру.<br>Әлеге программаны гамәлгә ашыру ахыр чиктә халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә, аларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга, мәгълүматлылыкны арттыруга, шулай ук социаль һәм сәяси тотрыклылыкны тәэмин итүгә китерәчәк. |

## II. Муниципаль программаны тормышка ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән муниципаль программа хәл итүгә юнәлтелгән проблемаларны да кертеп

Заманча берләшмәләр үзен максатлы төркем белән анык тәңгәлләштерүче халыкның оешкан төркемнәренә формалашкан өлеше булып тора. Алар җәмгыятьнең аерым төркемнәренең җәмәгатьчелек фикерен белдерәләр, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә оешкан төстә катнаша алалар.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар гражданлык җәмгыятенең оештыру нигезе булып каралырга мөмкин. Халыкның төрле төркемнәре мәнфәгатьләрен чагылдырып, беренче чиратта социаль якланмаганнарны, иҗтимагый оешмалар

муниципаль берәмлекләр үсешендә мөһим роль уйный.

Районны үстерү буенча аерым карарлар кабул итү процессына җәлеп итү, әлеге карарларны тормышка ашыруның барышын тикшереп тору мөмкинлеге, халыкның тормыш дәрәҗәсен, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, шулай ук төбәктә социаль һәм сәяси тотрыклылыкны тәэмин итү халыкта гражданлык җаваплылыгы барлыкка килүгә, актив тормыш позициясен формалаштыруга, үзидарәнең һәм үзидарәнең яңа формаларын үстерүгә ярдәм итә.

Бүгенге көндә күпчелек социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен бердәнбер даими яшәү чыганагы булып әгъзалык кертемнәре тора. Мондый оешмаларның якынча яртысы шәхси иганәчелек кертемнәре, иганәчеләр ярдәме, сирәк кенә булса да алынган грантлар хисабына яши. Коммерциячел булмаган оешмаларның күбесе тәҗрибә булмау сәбәпле, хуҗалык эшчәнлеген алып бара алмый һәм ахыр чиктә үз эшчәнлеген туктата.

Белгечләр фикеренчә, илдә иҗтимагый секторның якын киләчәктә үсеше иң мөһим өч фактор белән билгеләнә:

- социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт һәм бизнес тарафыннан ярдәм (финанслау) итү дәрәҗәсе;
- социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт контроле дәрәҗәсе;
- гражданнарның социаль активлыгы дәрәҗәсе.

"Коммерцияле булмаган оешмалар турында" Федераль закон бәйсез коммерцияле булмаган оешмаларга дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан ярдәм итү мөмкинлеген күздә тота. Мондый ярдәм һәм хезмәттәшлек ике якның да төп мәнфәгатьләренә туры килә. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар хакимият белән халык ихтыярын белдерү арасында арадашчы ролен башкара, иҗтимагый һәм социаль мөнәсәбәтләрне гуманизацияләүгә ярдәм итүче кыйммәтләрне тулысынча актуальләштерә һәм шуның белән җәмгыятьне тотрыклыландыра.

Хәзерге вакытта хакимият органнары тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә ихтыяҗ саклана, өлкән яшьтәге кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту, инвалидларны һәм аларның гаиләләрен социаль адаптацияләү, массакүләм спортны, мәдәни, туган якны өйрәнү һәм экологик эшчәнлекне үстерү, гражданнарның социаль куркыныч тәртипләрен профилактикалау һәм башка шундый хезмәт күрсәтүләргә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларны җәлеп итәргә мөмкин булыр иде.

Зәй муниципаль районында 4 социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма эшли:

- Ветераннар советы,
- Инвалидлар җәмгыяте,
- Күрү буенча инвалидлар җәмгыяте,
- "Чернобыль"Берлеге иҗтимагый оешмасы.

Зәй муниципаль районы ветераннар советы сугыш, хезмәт, кораллы көчләр һәм хокук саклау органнары ветераннарын берләштерә. Аның составына Зәй шәһәренең, авыл җирлекләренең ветераннар оешмалары керә.

Инвалидлар җәмгыятендә исәптә 3000 инвалид тора. Анда сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга зур игътибар бирелә: спорт ярышлары үткәрелә, боз сараена, бассейнга бушлай йөрү мөмкинлеге тудырылган. Җәмгыятьтә "Надежда", "Танышу", "Шахмат-шашка" клублары эшли.

Күрү буенча инвалидлар җәмгыяте 1997 елда оешты. Хәзерге вакытта шәһәр һәм район инвалидлары исәптә тора. Җәмгыятьнең һәр әгъзасы аерым контрольдә тора, беренче чиратта хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән: тома сукыр һәм урын өстендәге инвалидларга зур игътибар бирелә. Күрмәүче инвалидларны иртә ачыклау һәм аларга кичектергесез консультация ярдәме күрсәтү буенча эш җайга салынган.

"Чернобыль Берлеге" иҗтимагый оешмасы ЧАЭСтагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучылаарны, махсус риск бүлекчәләрендә катнашучыларны, "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларны, читләштерү зонасыннан эвакуацияләнүчеләрне берләштерә. Оешма 1992 елдан эшли. Квалификацияле юридик ярдәм күрсәтү эше яхшы оештырылган, аның ярдәмендә җәмгыять әгъзалары судларда җиңеп һәм үзләренә тиешле социаль түләүләрне сизелерлек арттырдылар. Авыруларның өйләренә бару оештырылган, социаль-мәдәни тернәкләндерү эше алып барыла.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның муниципаль район тормышында әһәмияткә ия булуын исәпкә алып, программаны гамәлгә ашыру күп кенә социаль проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән: авыр тормыш хәлендә калган кешеләргә ярдәм күрсәтү; сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру; гражданнарның иҗади һәм социаль активлыгын үстерү; гражданлык җаваплылыгын арттыру; яшьләргә патриотик тәрбия бирү; халыкның хәбәрдарлыгын арттыру һәм башкалар.

Зәй муниципаль районында булган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар әгъзалары гына түгел, башка категория гражданнарның да (балалы гаиләләр; авыр тормыш хәленә эләккән гражданнар; иректән мәхрүм итү урыннарыннан кайткан, акчалары булмаган гражданнар һәм башкалар) өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ булуын исәпкә алып, аларга матди ярдәм күрсәтү зарурлыгы туа. Әлеге максатларда муниципаль бюджеттан әлеге программа кысаларында гражданнарга матди ярдәм күрсәтү өчен акчалар карала.

## III. Муниципаль программаның төп максатлары, бурычлары

Төп максат - Зәй муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү һәм аларның эшчәнлеген җәелдерү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк:

1. Зәй муниципаль районының өлкән яшьтәге гражданнары, инвалидлары, шулай ук башка аз якланган халык төркемнәре статусын саклап калу максатыннан социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру һәм тәэмин итү;
2. Зәй муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга финанс, мөлкәти, мәгълүмати, консультация ярдәме күрсәтү;
3. Зәй муниципаль районы территориясендә актуаль социаль проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның проектларын, инновацион социаль хезмәт күрсәтүләрен гамәлгә ашыруга ярдәм итү;
4. Районның иҗтимагый тормышында актив катнашучы гражданнар санын арттыруга ярдәм итү;
5. Социаль эшкуарлыкны үстерү;
6. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар хезмәткәрләренең һәм волонтерларның белемен күтәрү һәм укыту.

## Программаны тормышка ашыруның вакыты һәм этаплары:

Программа, алдагы елларда дәвам ителүне (озайтылуны) исәпкә алып, 2022-2025 елларга исәпләнгән. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү өчен бюджеттан тыш чыганакларны җәлеп итү рөхсәт ителә. Программаны финанс белән тәэмин итү муниципаль бюджет һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар

хисабына гамәлгә ашырыла.

**Программа индикаторлары**

| Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар саны, бер. | 4 (бер.) | 5 (бер.) | 6 (бер.) | 7 (бер.) |
| Муниципаль район территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар саны арту (берәмлек) | - | 1 | 1 | 1 |
| Муниципаль район территориясендә коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегендә катнашучы гражданнарның өлеше арту (%) | 100% | 105% | 110% | 115% |
| Җирле бюджеттан субсидия алган проектларны гамәлгә ашырачак СО НКО өлеше (%) | 60% | 80% | 100% | 100% |

## IV. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Муниципаль бюджеттан программаны финанслауның гомуми күләме 6 565 120 сум тәшкил итә

| Финанслау чыганаклары | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | Барысы |
|---|---|---|---|---|---|
| **Муниципаль бюджет** | **250 000** | **2 095 040** | **2 105 040** | **2 115 040** | **6 565 120** |
| **Программа буенча барлыгы** | **250 000** | **2 095 040** | **2 105 040** | **2 115 040** | **6 565 120** |

Финанслау күләме фаразлау характерына ия һәм чираттагы финанс чорына муниципаль бюджетны формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. Муниципаль программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге муниципаль дәрәҗәдә халыкның активлыгын характерлаучы сыйфат һәм сан күрсәткечләре буенча бәяләнә.

Чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә көтелә:

- юридик зат статусына ия булган коммерциячел булмаган оешмалар саны арту,
- муниципаль берәмлектә үткәрелгән иҗтимагый акцияләр һәм чаралар саны арту.

## V. Программаның икътисади һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Муниципаль программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль программаның максатларына ирешү дәрәҗәсен бәяләү һәм бурычларны хәл итү нигезендә муниципаль программа күрсәткечләренең (индикаторларының) фактта ирешелгән күрсәткечләрен һәм муниципаль программада каралган пландагы күрсәткечләрен билгеләү юлы белән «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль

программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 29 октябрендәге 2496 номерлы ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарындагы таләпләргә туры китереп үткәрелә.

## VI. Чаралар

| № п/п | Чараларның исеме | Программаны тормышка ашыруга чыгымнар суммасы (сум) | | | | Барысы (сумн.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | |
| **Ветеранар советы** | | | | | | |
| 1 | Фатир ремонтлауда ветераннарга матди ярдәм күрсәтү | - | 100 000 | 100 000 | 100 000 | 300 000 |
| 2 | Транспорт чыгымнары: чараларда катнашучыларны йөртү | - | 20 000 | 20 000 | 20 000 | 20 000 |
| 3 | Бөек Ватан сугышы ветераннарын, пенсионерларны юбилейлары белән котлау (90, 95, 100-яшь тулу уңаеннан) | 50 000 | 120 000 | 120 000 | 120 000 | 410 000 |
| 4 | Ветераннарга газета яздыруны оештыру | - | 80 000 | 80 000 | 80 000 | 240 000 |
| 5 | Эш йомгаклары буенча бүләкләү: рәисне 10 000 сум х 4 квартал = 40 000 сум секретарьне: 3 000 сум х 4 квартал = 12 000 руб. | 52 000 | 52 000 | 52 000 | 52 000 | 208 000 |
| 6 | «Җиңү көнен» бәйрәм итүне оештыру Ветераннарны ашатуны оештыру 160 кеше х 500 сум= 80 000 сум | - | 80 000 | 80 000 | 80 000 | 240 000 |
| 7 | Өлкәннәр көне уңаеннан үзәк район хастаханәсендә дәваланучы өлкән яшьтәге кешеләрнең хәлен белү. Азык-төлек җыелмасы: 80 кеше х 400 сум = 32 000 сум | - | 32 000 | 32 000 | 32 000 | 96 000 |
| 8 | Бөек Ватан сугышында катнашучыларга азык-төлек җыелмалары: 9 кеше х 4 000 сум = 36 000 сум | - | 36 000 | 36 000 | 36 000 | 108 000 |
| 9 | Канцелярия товарлары сатып алу | - | 3 000 | 3 000 | 3 000 | 9 000 |
| | **БАРЫСЫ:** | **102 000** | **523 000** | **523 000** | **523 000** | **1 671 000** |
| **Инвалидлар җәмгыяте** | | | | | | |
| 1 | Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү 2023 ел: 18 кеше х 2 500 сум = 45 000 сум 2024 ел: 20 кеше х 2 500 сум = 50 000 сум | - | 45 000 | 50 000 | 55 000 | 150 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2025 ел: 22 кеше х 2 500 сум = 55 000 сум | | | | | |
| 2 | Газеталарга яздыруны оештыру | - | 35 000 | 40 000 | 45 000 | 120 000 |
| 3 | Инвалидлар декадасын оештыру һәм үткәрү: сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен бәйрәм, «Шатлык» халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең максатчан төркеменә, «Чукрак-телсезләр» клубына йөрүчеләр өчен 50 кеше х 500 сум = 25 000 сум | - | 25 000 | 25 000 | 25 000 | 75 000 |
| 4 | Социаль хезмәт күрсәтү бүлеге хезмәтләреннән файдаланучы өлкәннәр һәм 18 яшьтән өлкәнрәкләр арасында психик сәламәтлекләре бозылган затларның бәйрәм очрашуы Ашату, чәй эчү оештыру 30 кеше х 500 сум = 15 000 сум | - | 15 000 | 15 000 | 15 000 | 45 000 |
| 5 | Халыкара инвалидлар көнен бәйрәм итүгә багышланган чара. Өстәл әзерләү. | - | 50 000 | 50 000 | 50 000 | 150 000 |
| 6 | Эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү<br>- җәмгыять рәисе: 10 000 сум х 4 квартал = 40 000 сум<br>- җәмгыять секретаре: 8 000 сум х 4 квартал = 32 000 сум. | 40 000<br>32 000 | 40 000<br>32 000 | 40 000<br>32 000 | 40 000<br>32 000 | 160 000<br>128 000 |
| 7 | Телефон элемтәсе өчен түләү | - | 7 000 | 7 000 | 7 000 | 21 000 |
| 8 | Канцелярия товарлары сатып алу | - | 5 000 | 5 000 | 5 000 | 15 000 |
| 9 | Түләүсез чәч кистерү: 40 кеше х 400 сум = 8 000 сум | - | 16 000 | 16 000 | 16 000 | 48 000 |
| 10 | Юл сәфәре чыгымнары | - | 5 000 | 5 000 | 5 000 | 15 000 |
| | **БАРЫСЫ:** | **72 000** | **275 000** | **285 000** | **295 000** | **927 000** |
| **Күрү буенча инвалидлар җәмгыяте** | | | | | | |
| 1 | Республика слетында катнашу Эш сәфәре чыгымнары (юл йөрү билетлары) | - | 8 000 | 8 000 | 8 000 | 24 000 |
| 2 | Инвалидларның спорт ярышларында һәм фестивальләрдә катнашуы Эш сәфәре чыгымнары | 4000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 34 000 |
| 3 | Авыр тормыш хәлендә калган җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү: 10 кеше х 2 500 сум = 25 000 сум | - | 25 000 | 25 000 | 25 000 | 75 000 |
| 4 | Җәмгыять әгъзаларын газеталарга яздыруны оештыру | - | 16 000 | 16 000 | 16 000 | 48 000 |
| 5 | Күрү сәләте буенча инвалидларга күзлек сатып алуда матди ярдәм күрсәтү | - | 20 000 | 20 000 | 20 000 | 60 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | "Ак таяклылар көне"н оештыру һәм уздыру. 20 кешегә чәй өстәле көйләү | - | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 30 000 |
| 7 | Күрү сәләте чикләнгән балалар өчен инвалидлар декадасы һәм Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан чаралар оештыру һәм уздыру. Ашатуны оештыру:<br>25 кешех 400 сум = 10 000 сум | - | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 30 000 |
| 8 | Тома сукырларның өйләренә бару (күрмәүчеләрнең)<br>Азык җыелмасы:<br>36 кеше х 300 сум =10 800 сум | - | 10 800 | 10 800 | 10 800 | 32 400 |
| 9 | Хуҗалык чыгымнары<br>Канцелярия товарлары сатып алу | - | 5 000 | 5 000 | 5 000 | 15 000 |
| 10 | Поощрение по итогам работы: Эш йомгаклары буенча бүләкләү:<br>- җәмгыять рәисен 10 000 сум х 4 квартал = 40 000 сум<br>- секретарен 3 000 сум х 4 квартал = 12 000 сум | 40 000<br>12 000 | 40 000<br>12 000 | 40 000<br>12 000 | 40 000<br>12 000 | 160 000<br>48 000 |
| 11 | Интернет өчен түләү | - | 12 240 | 12 240 | 12 240 | 36 720 |
| | **БАРЫСЫ:** | **56 000** | **179 040** | **179 040** | **179 040** | **593 120** |
| **«Чернобыль Берлеге» иҗтимагый оешмасы** | | | | | | |
| 1 | Ветераннарны газеталарга яздыруны оештыру | - | 7 000 | 7 000 | 7 000 | 21 000 |
| 2 | ЧАЭСта һәлакәт уңаеннан Хәтер көнен оештыру һәм үткәрү<br>(26 апрель)<br>Иҗтимагый оешма ветераннарына матди ярдәм күрсәтү<br>50 кеше х 500 сум = 25 000 сум<br>Һәйкәлгә салу өчен чәчәкләр сатып алу | -<br>- | 25 000<br>15 000 | 25 000<br>15 000 | 25 000<br>15 000 | 75 000<br>45 000 |
| 3 | Авыр тормыш хәленә юлыккан җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү<br>12 кеше х 2 000 сум = 24 000 сум | - | 24 000 | 24 000 | 24 000 | 72 000 |
| 4 | Җәмгыять рәисен эше йомгаклары буенча бүләкләү:<br>10 000 сум х 4 квартал = 40 000 сум | 20 000 | 40 000 | 40 000 | 40 000 | 130 000 |
| | **БАРЫСЫ:** | **20 000** | **111 000** | **111 000** | **111 000** | **343 000** |
| **Гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү** | | | | | | |
| 1 | Мохтаҗ гражданнарга матди ярдәм күрсәтү | - | 1 000 000 | 1 000 000 | 1 000 000 | 3 000 000 |
| 2 | Сәяси золым корбаннарын искә алу көне (30 октябрь)<br>Матди ярдәм:<br>2023: 14 кеше х 500 сум = 7 000 сум<br>2024: 14 кеше х 500 сум = 7 000 сум<br>2025: 14 кеше х 500 сум = 7 000 сум | - | 7 000 | 7 000 | 7 000 | 21 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **БАРЫСЫ** | **-** | **1 007 000** | **1 007 000** | **1 007 000** | **3 021 000** |
| | **ПРОГРАММА БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **250 000** | **2 095 040** | **2 105 040** | **2 115 040** | **6 565 120** |

## VII. Муниципаль программа нәтиҗәләрен бәяләүнең максатлары, бурычлары, индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| Ярдәмче программалар ның аталышы | Төп чараларның аталышы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Индикаторларның күрсәткече | | | | Чыганакны күрсәтеп, финанслау | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Ветераннарга матди ярдәм күрсәтү буенча чаралар | - Ветераннарга фатирларын төзекләндерүгә матди ярдәм күрсәтү;<br>- Транспорт чыгымнары: чараларда катнашучыларны йөртү;<br>- Өлкән яшьтәге гражданнарны 90 яше тулу белән котлау;<br>- Ветераннарга газета яздыруны оештыру;<br>- Җәмгыять рәисен, җәмгыять секретарен эш йомгаклары буенча бүләкләү; | ЗМР Башкарма комитеты, подряд оешмасы, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | 2022-2025 еллар | 2 | 9 | 9 | 9 | 102 000 | 523 000 | 523 000 | 523 000 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - «Җиңү» бәйрәмен үткәрү. Ветераннарны хөрмәтләүне оештыру;<br>- Өлкәннәр көне уңаеннан Зәй үзәк район хастаханәсендә ятучы өлкәннәр янында булу. Азык-төлек җыелмасы<br>- Интернат-йортларда яшәүче өлкән яшьтәге кешеләр янына бару;<br>- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга азык-төлек җыелмалары әзерләү; Канцелярия товарлары сатып алу. | | | | | | | | | | |
| Инвалидларга матди ярдәм күрсәтү буенча чаралар | -Мөмкинлекләре чикләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү; | ЗМР Башкарма комитеты, инвалидлар җәмгыяте, ТР Хезмәт, | 2022-2025 еллар | 1 | 10 | 10 | 10 | 72 000 | 275 000 | 285 000 | 295 000 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - Газеталарга язылуны оештыру;<br>- Инвалидлар декадасын оештыру һәм үткәрү: сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен бәйрәм, «Шатлык» халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең максатчан төркеменә, «Чукрак-телсезләр» клубына йөрүчеләр өчен;<br>-Социаль хезмәт күрсәтү бүлеге хезмәтләреннән файдаланучы өлкәннәр һәм 18 яшьтән өлкәнрәкләр арасында психик сәламәтлекләре бозылган | халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | затларның бәйрәм очрашуы Ашату, чәй эчү оештыру<br>- Халыкара инвалидлар көнен бәйрәм итүгә багышланган чара.<br>Чәй өстәле әзерләү;<br>-Җәмгыять рәисен, җәмгыять сәркатибен эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү;<br>- Телефон элемтәсе өчен түләү;<br>- Канцелярия товарлары сатып алу;<br>- Бушлай чәч кистерү;<br>- Эш сәфәре чыгымнары | | | | | | | | | | |
| Күрү буенча инвалидларга матди ярдәм күрсәтү буенча | - Республика слетында катнашу<br>Эш сәфәре чыгымнары (юл | ЗМР Башкарма комитеты, күрү сәләте буенча | 2022-2025 еллар | 2 | 11 | 11 | 11 | 56 000 | 179 040 | 179 040 | 179 040 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | билетлары);<br>- Инвалидлар өчен спорт ярышларында һәм фестивальләрдә катнашу<br>Эш сәфәре чыгымнары;<br>- Авыр тормыш хәленә юлыккан җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү;<br>- Җәмгыять әгъзаларына газеталарга язылуны оештыру;<br>- Күрү сәләте буенча инвалидларга күзлек сатып алу өчен матди ярдәм күрсәтү;<br>- "Ак таяклылар көне"н оештыру һәм уздыру. 20 кешегә чәй өстәле көйләү;<br>- Күрү сәләте чикләнгән балалар өчен инвалидлар | инвалидлар җәмгыяте,<br>ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | декадасы һәм Яңа ел бәйрәмнәре уңаеннан чаралар оештыру һәм уздыру. Ашатуны оештыру;<br>- Хуҗалык чыгымнары Канцелярия товарлары сатып алу;<br>- Җәмгыять рәисен эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү;<br>- Юл йөрү билетын түләү;<br>- Интернет өчен түләү | | | | | | | | | | |
| ЧАЭСта һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга матди ярдәм күрсәтү буенча чаралар | - Ветераннарга газеталар яздыруны оештыру;<br>- ЧАЭСта һәлакәт уңаеннан Хәтер көнен оештыру һәм үткәрү (26 апрель) Иҗтимагый | ЗМР Башкарма комитеты, «Чернобыль берлеге” иҗтимагый оешмасы, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм | 2022-2025 еллар | 1 | 4 | 4 | 4 | 20 000 | 111 000 | 111 000 | 111 000 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оешма ветераннарына матди ярдәм күрсәтү Һәйкәлгә кую өчен чәчәкләр сатып алу;<br>- Авыр тормыш хәленә юлыккан җәмгыять әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү;<br>- Җәмгыять рәисен эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү. | социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | | | | | | | | | |
| Матди ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның ярдәм күрсәтелмәгән категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары | - Мохтаҗ гражданнарга матди ярдәм күрсәтү;<br>- Сәяси репрессия корбаннарын искә алу көненә матди ярдәм (30 октябрь); | ЗМР Башкарма комитеты, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге | 2022-2025 еллар | 0 | 2 | 2 | 2 | 0 | 1 007 000 | 1 007 000 | 1 007 000 |
| **Барысы:** | | | | 6 | 36 | 36 | 36 | 250 000 | 2 095 040 | 2 105 040 | 2 115 040 |